ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза, 422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагужа авылы, 422586

Тел.: (84379) 35-5-70, факс: (84379) 35-5-70.

17.11.2023 01

На №______________от________________

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Патрикеево авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Патрикеево авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар җибәрү:- Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү, мемориаль такталар кую, Патрикеево авылында һәйкәл территориясен әйләндереп алу, мәсьәләсе буенча 2022 елның 31 октябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 88 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан 45 граждан кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 45 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Патрикеево авылы территориясендә гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип таныргa.

2. «2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Патрикеево авылы территориясендә теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән билгеләнгән гражданнарның ташламалы категориясеннән тыш, һәр балигъ булган кешедән Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Патрикеево авылында 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар җибәрү:- Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү, мемориаль такталар кую, Патрикеево авылында һәйкәл территориясен әйләндереп алу белән килешәсезме?» - дигән сорау буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Патрикеево авылындагы гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Карагуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Җыелышта рәислек итүче: Д.В.Плохов